**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 елның «01» сентябреннән № 246

**«Муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәсен төзү хокукына бәяне күтәрүгә ачык аукцион оештыру һәм үткәрү турында»**

Муниципаль мөлкәтне нәтиҗәле файдалану максатыннан 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы «Көндәшлекне яклау турында» гы Федераль законга, 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» гы Федераль законга, РФ Граждан кодексына, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Уставына таянып, карар бирәм:

1. Муниципаль милекне арендалау килешмәсе төзү хокукын сату буенча ачык аукцион үткәрергә.

2. Аренда шартнамәсен төзү хокукын сату буенча ачык аукционга куела торган муниципаль мөлкәт исемлеген расларга (1нче кушымта).

3. Муниципаль милекне арендалау шартнамәсен төзү хокукына бәяне күтәрүгә ачык аукцион үткәрү буенча аукцион комиссиясе составын расларга (2 нче кушымта).

4. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына үткәрелгән аукцион нәтиҗәләре буенча сатуларда җиңүче белән әлеге карарның 1 нче кушымтасында күрсәтелгән муниципаль милекне арендалау килешүен төзергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе** **Р.Р. Фасахов**

Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2015 елның «01» сентябреннән
№ 246 номерлы карарына
1 нче кушымта

Аренда шартнамәсен төзү хокукын сату буенча ачык аукционга куела торган муниципаль мөлкәт исемлеге

1. 5 елга муниципаль милекне арендалау шартнамәсен төзү хокукы:

| лот номеры | Объект исеме | Мәйданы (кв. м.) | Адрес: (Татарстан Республикасы) | Рөхсәт ителгән куллану төре | Аренда хокукының башлангыч бәясе (сум) | Аукцион адымы (сум) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 9 нчы бүлмә | 10,1 | Яңа Чишмә авылы, Совет ур., 80 | офис урнаштыру өчен | 1820,00 | 91,00 |

Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитеты
эшләре белән идарә итүче М.Д.Губкина

Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2015 елның «01» сентябреннән
№ 246 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Аренда шартнамәсен төзү хокукын сату буенча бәяне күтәрүгә аукцион үткәрү буенча аукцион комиссиясе составы**

**Комиссия рәисе:**

| | | |
|---|---|---|
| Исхакова Л.К. | - | Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары |

**Комиссия әгъзалары:**

| | | |
|---|---|---|
| Гордеева Н.А. | - | Яңа Чишмә муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе |
| Завалишина Л.Л. | - | Яңа Чишмә муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе |
| Митько А.В. | - | Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль заказ бүлеге башлыгы |
| Попкова Н.В. | - | Яңа Чишмә муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасының әйдәп баручы белгече |

Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитет
эшләре белән идарә итүче М.Д. Губкина